«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының «Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга юнәлдерелгән социаль реклама конкурсын үткәрү турында» 2021 елның 12 августындагы 120-п номерлы боерыгы (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән)

«Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 16 октябрендәге 764 номерлы карары белән расланган «Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» Татарстан Республикасы дәүләт программасында каралган «Халык арасында наркоманияне профилактикалау» процесс чаралары комплексын гамәлгә ашыру кысаларында БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга юнәлдерелгән социаль реклама конкурсын үткәрү турында кушымта итеп бирелә торган Нигезләмәне расларга.
2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе урынбасары И.Ф. Миргалимовка йөкләргә.

Җитәкче А.С. Сәлимгәрәев

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында
2021 елның 14 сентябрендә теркәлде
Теркәү номеры – 7901

**Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга юнәлдерелгән социаль реклама конкурсын үткәрү турында Нигезләмә**
**(«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2021 елның 12 августындагы 120-п номерлы боерыгы белән)**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. «Әлеге Нигезләмә «Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 16 октябрендәге 764 номерлы карары белән расланган «Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» Татарстан Республикасы дәүләт программасында каралган «Халык арасында наркоманияне профилактикалау» процесс чаралары комплексын гамәлгә ашыру кысаларында сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга юнәлдерелгән социаль реклама конкурсын (алга таба – Конкурс) үткәрү тәртибен, оештыру һәм үткәрү шартларын билгели.
1.2. Конкурсның оештыручысы – Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр

министрлыгы (алга таба – Министрлык) ярдәме белән, «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы (алга таба – Агентлык, Оештыручы).

1.3. Конкурс 30 декабрьгә кадәр үткәрелә.

Конкурсны үткәрү турындагы мәгълүмат Оештыручының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://tatmedia.tatarstan.ru,) «Яңалыклар», «Конкурслар» бүлекләрендә (алга таба – Оештыручының рәсми сайты) һәм Министрлыкның рәсми сайтында (https://16.мвд.рф) (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты) урнаштырыла. Конкурс үткәрү турындагы мәгълүматта Конкурсны үткәрү шартлары, номинацияләр, шул исәптән махсус номинация, конкурс эшләрен бәяләү критерийлары һәм тәртибе, Конкурска гаризалар кабул ителә башлау һәм тәгәлләнү сроклары, урыны, бүләкләрнең күләме һәм аларны тапшыру рәвеше, шулай ук Конкурс нәтиҗәләрен игълан итү тәртибе һәм сроклары күрсәтелә.

1.4. Конкурста җиңүчеләргә чәчәкләр, дипломнар һәм акчалата премияләр тапшырыла.

1.5. Конкурска бер генә гариза тапшырылса, яисә бер гариза да тапшырылмаса, Конкурс үткәрелмәгән дип санала.

## 2. Конкурсның максатлары һәм бурычлары

2.1. Конкурсның максаты – сәламәт яшәү рәвеше культурасы булдыруның нәтиҗәлелеген арттыру.

2.2 Конкурсның төп бурычлары:

наркотиклар куллануның куркыныч нәтиҗәләрен аңлаучы иҗтимагый фикер булдыру, сәламәт яшәү рәвешен актив пропагандалау;

җәмәгатьчелекне, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чараларын, наркотикларга каршы пропагандага җәлеп итү;

халыкның хокукый культурасын арттыру, наркотикларның законсыз әйләнеше өлкәсендә хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау.

2.3. Конкурсны оештыру һәм үткәрү гавамилык, ачыклык, Конкурста катнашучыларның тигез хокуклылыгы, гаризаларны конкурс нигезендә карау принципларына нигезләнә.

## 3. Конкурсның номинацияләре

3.1. Конкурс түбәндәге номинацияләрдә үткәрелә:

«Социаль челтәрләргә урнаштыру өчен наркотикларга каршы реклама видеороликгына иң яхшы сценарий» (1, 2, 3 урын).

«Наркотикларга каршы һәм /яисә сәламәт яшәү рәвешен пропагандалаучы мем, рәсемнәр сериясе» (1, 2, 3 урын).

«Наркотикларга каршы һәм /яисә сәламәт яшәү рәвешен пропагандалаучы иң яхшы текст, шигырь, җыр, канатлы гыйбарә, шигарь» (1, 2, 3 урын).

«Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга өлеш керткән өчен» махсус номинациясе (1,2 урын).

## 4. Конкурска гариза бирүчеләр һәм конкурста катнашучылар

4.1. Конкурска гариза бирүчеләр – Конкурс турында нигезләмәнең 5.2. пункты нигезендә документлар тапшырган авторлар, авторлар коллективлары, аерым журналистлар, журналистлар коллективлары, массакүләм мәгълүмат чаралары (законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән) редакцияләре, авторлар, иҗат коллективлары һәм төркемнәре (алга таба – гариза бирүчеләр).

4.2. Конкурста катнашучылар – тапшырылган эшләре Конкурста катнашырга рөхсәт ителгән гариза тапшыручылар (алга таба – катнашучылар).

4.3. Конкурста 14 яшькә җиткән, хокукка сәләтле затлар катнаша ала, алар конкурс эшләрен шәхсән яисә коллектив составында тапшырырга мөмкин.

4.4. Конкурста катнашу эшләрне алга таба түләүсез, ләкин авторын, журналистын, авторлык яисә журналистлар коллективын, ммч редакциясен, шулай ук чыганагын күрсәтеп, мәгълүмати, фәнни, белем бирү һәм мәдәни максатларда файдалануга ризалык бирүне аңлата.

4.5. Өченче затларның авторлык хокукларын үтәмәгән өчен җаваплылык эшләрне тәкъдим иткән катнашучыларга йөкләнә.

4.6. Гариза бирүче Конкурсның бер номинациясендә катнашу өчен бер генә гариза бирә ала.

4.7. Конкурска гариза бирүче берничә номинация буенча документлар тапшыра ала, бу очракта конкурс комиссиясе тарафыннан карала торган документлар әлеге Нигезләмәнең 5.2. пункты нигезендә һәрбер номинация буенча аерым әзерләнергә тиеш. Бер үк эш төрле номинацияләргә тәкъдим ителә алмый.

## 5. Конкурсны үткәрү шартлары

5.1. Конкурста катнашу өчен моңа кадәр үткәрелгән Конкурска йомгак ясау датасыннан башлап чираттагы Конкурска гаризалар кабул итү тәгәлләнәчәк датага кадәр дөнья күргән конкурс эшләре кабул ителә.

5.2. Гариза түбәндәге документлар теркәлеп тапшырыла:

а) конкурс эшләре – наркотикларга каршы юнәлештәге видеофильм яисә видеоролик сценарийлары, наркотикларга каршы һәм /яисә сәламәт яшәү рәвешен пропагандалаучы мем, рәсемнәр сериясе, наркотикларга каршы һәм /яисә сәламәт яшәү рәвешен пропагандалаучы иң яхшы текст, шигырь, җыр, канатлы гыйбарә, шигарь. Өстәмә рәвештә иллюстрацияләр, дизайн-макетлар, видео һ.б. тапшырылырга мөмкин.

б) катнашу өчен анкета (әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтага таянып);

в) юридик зат буларак теркәлгән массакүләм мәгълүмат чарасы редакцияләре өчен:

юридик затны салым органында исәпкә кую турында таныклык (ИНН)

(күчермәсе);

юридик зат җитәкчесен вазыйфага билгеләп кую турында боерык (күчермәсе);

гамәлгә кую документлары (күчермәләре);

ММЧ теркәү турында таныклык (күчермәсе) йә теркәлгән массакүләм мәгълүмат чаралары реестрыннан өземтә;

г) юридик зат булмаган массакүләм мәгълүмат чарасы редакцияләре өчен:

массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турында таныклык (күчермәсе) йә теркәлгән массакүләм мәгълүмат чаралары реестрыннан өземтә;

массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе уставы яисә, массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясендә кимендә 10 кеше эшләсә, “Массакүләм мәгълүмат чаралары турында” 1991 елның 27 декабрендәге 2124-I номерлы Россия Федерациясе Законының (алга таба – ММЧ турында Закон) 20 статьясы нигезендә аны алмаштыра торган шартнамә;

баш мөхәррирне вазыйфага билгеләп кую турында документ (күчермәсе);

д) уртак эшләр тәкъдим итә торган авторлар, иҗат коллективлары өчен:

шәхесне таныклаучы документ (күчермәсе);

әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымта нигезендә Персональ белешмәләрне эшкәртүгә, тапшыруга ризалык бирү;

персональ белешмәләр субъекты рөхсәт иткән персональ белешмәләрне таратуга ризалык (3 нче кушымта нигезендә);

Конкурска гариза бирүче 14 яшькә җиткән балигъ булмаган зат булса, 14 яшькә җиткән балигъ булмаганнарның ата-анасы (законлы вәкиле) ризалыгы белән рәсмиләштерелгән персональ белешмәләрне эшкәртүгә ризалык (әлеге Нигезләмәгә 4 нче кушымта);

Конкурска гариза бирүче 14 яшькә җиткән балигъ булмаган зат булса, 14 яшькә җиткән балигъ булмаганнарның ата-анасы (законлы вәкиле) ризалыгы белән рәсмиләштерелгән тарату өчен персональ белешмәләр субъекты тарафыннан рөхсәт ителгән персональ белешмәләрне эшкәртүгә ризалык (әлеге Нигезләмәгә 5 нче кушымта);

е) уртак эшләр тапшыра торган массакүләм мәгълүмат чаралары, иҗат коллективлары өчен – конкурс эшенә призлы урын бирелгән очракта, акчаны процентлап бүлешү турында килешү.

Әлеге пунктның «б» – «д» пунктчаларында күрсәтелгән документлар кәгазь вариантта (оешма җитәкчесенең имзасы белән тамгалана һәм оешма мөһере (булган очракта) сугыла) яисә сканердан чыгарып, PDF форматында электрон документ рәвешендә җибәрелә.

5.3. Конкурс эшләре Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе составындагы республикаларның дәүләт телләрендә, Россия Федерациясендә яшәүче башка халыклар телләрендә тапшырыла. Тәкъдим ителгән эш Россия Федерациясе составындагы республикаларның дәүләт телләрендә, Россия Федерациясендә яшәүче башка халыклар телләрендә тапшырылган очракта, татар телендә тапшырылган эшләрдән тыш, материалларның рус теленә тәрҗемәсе булырга тиеш, ул җитәкче имзасы белән таныклана.

5.4. Конкурска килгән эшләргә рецензия бирелми, алар кире кайтарылмый.

5.5. Гаризалар түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 420066, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт, «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгы, 6 кат, 608 нче кабинет. «Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга юнәлдерелгән социаль реклама конкурсына» дигән тамга белән Телефон: 8 (843) 570-31-12.

5.6. Документларның Агентлыкка килгән көне аларны тапшыру датасы дип санала.

5.7. Конкурста катнашуга рөхсәт бирмәү өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

гаризаның әлеге Нигезләмәнең 5.1. – 5.3. пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яисә гаризага әлеге Нигезләмәнең 5.2. пунктында каралган документларны теркәмәү;

гаризаны билгеләнгән срокны бозып тапшыру;

сурәтендә яисә тавышында хилафлыклар булган эшләр тәкъдим итү;

гариза биргәндә авторның номинацияне дөрес билгеләмәве;

гариза бирүче 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты статусына ия (авторлар коллективы әгъзасы (лары) «Чит ил йогынтысындагы затларның эшчәнлеген тикшереп тору турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил статусына ия булган очракта, чит ил агенты (лары) дип танылган заттан кала, авторлар коллективына рөхсәт ителә).

5.8. Конкурска кертелмәгән эшләр, гариза тапшыруның Оештыручының һәм Министрлыкның рәсми сайтларында күрсәтелгән срогында, кимчелекләре төзәтелеп, яңадан тәкъдим ителергә мөмкин.

5.9. Катнашучыга Конкурска кертелмәү турында хәбәр әлеге Нигезләмәнең 5.2 пунктында күрсәтелгән документларны алган мизгелдән алып бер эш көне дәвамында Оештыручы җитәкчесе (аның вазыйфаларын башкаручы зат) имзалаган һәм анкета-гаризада күрсәтелгән адреска җибәрелгән заказлы рәсми хат белән хәбәр ителә.

5.10. Гаризалар кабул итү тәмамланганнан соң килгән эшләр кабул ителми.

5.11. Конкурс йомгаклары конкурс комиссиясе тарафыннан ясала һәм беркетмә рәвешендә рәсмиләштерелә.

5.12. Җиңүчеләрне бүләкләү датасы турында Оештыручының һәм Министрлыкның рәсми сайтларына өстәмә мәгълүмат урнаштырыла.

5.13. Оештыручы эшләрне алга таба үз максатларында кулланырга мөмкин.

5.14. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (почта, командировка һ.б.) Гариза бирүче (Катнашучы) тарафыннан мөстәкыйль түләнә.

## 6. Конкурс эшләрен бәяләү

6.1. Конкурс эшләрен бәяләү критерийлары:

материалларны эшләүдә сәнгатьле алымнар куллану (өстәмә материаллар, иллюстрацияләр, видео булу) (0-10 балл);

эстетик яктан камиллек (гомуми кабул итү) (0-5 балл);

мәгънәсе (0-5 балл);

иҗади эшләнү дәрәҗәсе (0-10 балл).

## 7. **Конкурс комиссиясен оештыру һәм аның эшчәнлек тәртибе**

7.1. Конкурс комиссиясе – Конкурска тапшырылган эшләрне бәяли торган затлар төркеме.

7.2. Конкурста җиңүче – призлы урын алган катнашучы.

7.3. Конкурс комиссиясе 7 кеше составында төзелә, рәистән, рәис урынбасарыннан, комиссия әгъзаларыннан тора һәм Оештыручы тарафыннан раслана.

7.4. Конкурс комиссиясе үз эшен түләүсез башкара.

7.5. Конкурс комиссиясенең эше утырышларда гамәлгә ашырыла. Утырышта комиссия әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, утырыш тулы хокуклы дип санала.

7.6. Конкурс комиссиясе эшенә рәис җитәкчелек итә. Комиссия рәисе булмаганда, рәис вазыйфалары урынбасарына йөкләнә.

7.7. Конкурс комиссиясе әгъзалары конкурска тапшырылган эшләрне әлеге Нигезләмәнең 6 пунктында күрсәтелгән Конкурс эшләрен бәяләү критерийлар нигезендә бәяли.

7.8. 2024 елның 13 маеннан үз көчен югалтты. – «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2024 елның 27 мартындагы 56-п номерлы боерыгы

7.9. Бер номинациягә бер генә гариза тапшырылса, бер гариза да тапшырылмаса, тапшырылган гаризаларның берсе дә конкурс шартларына туры килмәсә, катнашкан эшләрнең берсе дә билгеләп үтәргә лаек дип танылмаса, Конкурс бу номинациядә үткәрелмәгән дип таныла һәм акчалар билгеләнгән башка җиңүчеләр арасында тигез итеп бүленә.

7.10. 2024 елның 13 маеннан үз көчен югалтты. – «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2024 елның 27 мартындагы 56-п номерлы боерыгы

7.11. Баллар саны буенча конкурс комиссиясе катнашучыларның рейтингын төзи. Рейтинг нигезендә җиңүчеләр билгеләнә.

7.12. Бертигез баллар җыйган катнашучылар булган очракта, җиңүче Конкурс комиссиясе әгъзаларының тавыш бирү юлы белән билгеләнә. Тавышлар саны тигез булса, комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч булып санала.

7.13. Җиңгән эш берничә авторныкы (физик затлар өчен)/берничә ММЧ (юридик затлар өчен) булса, ул эшне башкаруда катнашкан затлар арасында үзләре килешенгән күләмдә бүленә. Мондый килешү документлар белән бергә тапшырыла.

7.14. Конкурсны оештыручы оештыру-техник эшчәнлекне җайга салу, утырышны әзерләү һәм конкурс комиссиясе документациясен алып бару өчен җаваплы секретарь билгеләп куя.

7.15. Җаваплы секретарь конкурс комиссиясе составына керми һәм утырышларда тавыш бирү хокукыннан башка гына катнаша.

7.16. Конкурс комиссиясе утырышы уздырылган көннән алып биш эш көне эчендә Конкурс комиссиясе утырышы йомгаклары буенча беркетмә рәсмиләштерелә, аңа утырышта булган конкурс комиссиясе әгъзаларының имзасы салына, беркетмә конкурс комиссиясе рәисе яисә рәисе урынбасары тарафыннан раслана.

7.17. Конкурс йомгаклары турында мәгълүмат беркетмәгә кул куелганнан соң өч көн эчендә Агентлыкның һәм Министрлыкның рәсми сайтларына урнаштырыла.

## 8. Финанслау

8.1. Конкурсны оештыруга һәм үткәрүгә бәйле чыгымнар «Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 16 октябрендәге 764 номерлы карары белән расланган «Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» Татарстан Республикасы дәүләт программасында каралган «Халык арасында наркоманияне профилактикалау» процесс чаралары комплексын гамәлгә ашыру өчен агымдагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджетында каралган акчалар исәбеннән тотыла.

8.2. Гомуми приз фонды – 260,0 мең сум.

8.3. Конкурста җиңүчеләр түбәндәге тәртиптә бүләкләнә:

| | Номинацияләр | Урын | Сумма |
|---|---|---|---|
| | «Социаль челтәрләргә урнаштыру өчен наркотикларга каршы реклама видеоролигына иң яхшы сценарий» | 1 урын | 40,0 мең сум |
| | | 2 урын | 30,0 мең сум |
| | | 3 урын | 20,0 мең сум |
| | «Наркотикларга каршы һәм /яисә сәламәт яшәү рәвешен пропагандалаучы мем, рәсемнәр сериясе» | 1 урын | 40,0 мең сум |
| | | 2 урын | 30,0 мең сум |
| | | 3 урын | 20,0 мең сум |
| | «Наркотикларга каршы һәм /яисә сәламәт яшәү рәвешен пропагандалаучы иң яхшы текст, шигырь, җыр, канатлы гыйбарә, шигарь» | 1 урын | 20,0 мең сум |
| | | 2 урын | 15,0 мең сум |
| | | 3 урын | 10,0 мең сум |
| | «Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга өлеш керткән өчен» махсус номинациясе | 1 урын | 20,0 мең сум |
| | | 2урын | 15,0 мең сум; |

8.4. Юридик затларга акчалата премияләр Конкурс йомгаклары турында беркетмәгә имза салган мизгелдән алып 20 көн дәвамында, җиңүчеләрне игълан иткәннән соң, Анкетада күрсәтелгән исәп-хисап счетына күчерү юлы белән түләнә.

8.5. Физик затларга акчалата премияләр Конкурс йомгаклары турында беркетмәгә имза салган мизгелдән алып 20 көн дәвамында, җиңүчеләрне игълан иткәннән соң, Анкетада күрсәтелгән исәп-хисап счетына күчерү юлы белән түләнә.

## 9. Аерым шартлар

9.1. Оештыручылар түбәндәгеләргә хокуклы:

- әлеге Нигезләмәдә һәм Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында билгеләнгән очраклардан, шулай ук бәхәсле очраклардан тыш, Конкурста катнашучылар белән язмача йә башка төрле элемтәләргә кермәскә;

- эшләрне тапшыру срогының беренче яртысында Россия Федерациясе законнары таләпләрен (РФ ГК 1058 ст.) үтәп, Конкурсны туктатырга яки әлеге Нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә, бу хакта Оештыручының һәм Министрлыкның рәсми сайтында тиешле мәгълүмат урнаштырып, Катнашучыларга хәбәр итәргә.

9.2. Конкурс шартлары үзгәрү турында хәбәрнамә алганнан соң, Конкурста катнашучы эшләрне элек билгеләнгән шартларда кабул итүне яисә кертелгән үзгәрешләрне гамәлдә түгел дип тануны таләп итә алмый. Аның эшне Конкурсның яңа шартларына туры китереп үзгәртүе алга таба конкурста катнашырга мөмкинлек бирә.

9.3. «Чит ил йогынтысындагы затларның эшчәнлеген тикшереп тору турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә чит ил агенты дип танылган катнашучы чәчәкләр, диплом һәм акчалата премия белән бүләкләнми.

Бәйгедә катнашучы авторлар коллективы составында «Чит ил йогынтысындагы затларның эшчәнлеген тикшереп тору турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә чит ил агенты дип танылган катнашучы булса, мондый авторлар коллективы чәчәкләр, диплом һәм акчалата премия белән бүләкләнми.

Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга
юнәлдерелгән социаль реклама конкурсын үткәрү
турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

(тәкъдим ителә торган форма)

| Конкурста катнашу өчен анкета-гариза | |
|---|---|
| Гариза бирүче (ММЧ; авторның, авторлар коллективының Ф.И.Ат. ис.*) | |
| Номинация | |
| Конкурска тәкъдим ителгән эшнең исеме | |
| Аннотация | |
| Адрес | |
| Телефон | |
| Электрон почта | |
| Гариза бирүченең банк реквизитлары (банк исеме, ИНН һәм КПП, БИК, исәп-хисап счеты номеры | |
| ИНН (физик затлар өчен) | |
| СНИЛС (физик затлар өчен) | |

Түбәндәгеләрне раслыйм:

Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга юнәлдерелгән конкурска тәкъдим ителгән конкурс материалларында өченче затларның авторлык һәм башка хокукларын боза торган материаллар юк;

«Чит ил йогынтысындагы затларның эшчәнлеген тикшереп тору турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты статусым юк;

авторлар коллективы составында «Чит ил йогынтысындагы затларның эшчәнлеген тикшереп тору турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил статусына ия затлар юк**.

* Атасының исеме булган очракта күрсәтелә

** Гариза авторлар коллективы тарафыннан бирелгән очракта күрсәтелә

Дата ___________________

Имза _______________________ _______________________________

(фамилия)

Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга
юнәлдерелгән
социаль реклама конкурсын
үткәрү турында
нигезләмәгә
2 нче кушымта

(тәкъдим ителә торган форма)

**Персональ белешмәләрне эшкәртүгә ризалык**

Мин,_______________________________________________________________,
яшәү адресым_____________________________________________

_______________________________________________________________________,
шәхесне таныклаучы төп документым (паспорт)______________________

________________________________________________________________________________
_______________________________, «Персональ белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына (алга таба – оператор) (адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 йорт) сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга юнәлдерелгән социаль реклама конкурсында катнашуга бәйле рәвештә үземнең персональ белешмәләрне эшкәртүгә, аларны җыюны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, төгәлләштерүне (яңартуны, үзгәртүне), алардан файдалануны, аларны таратуны (шул исәптән башкаларга тапшыруны), үз исемемнән башка файдалануны, блокировать итүне, юкка чыгаруны да кертеп, ризалыгымны бирәм.

Эшкәртүгә ризалыгымны бирә торган персональ белешмәләрнең исемлеге:

| | |
|---|---|
| Эшкәртүгә ризалыгымны бирә торган персональ белешмәләрнең исемлеге: | (фамилия, исем, атасы исеме, җенес, туган көн һәм урын, гражданлык, шәхесне таныклаучы документның реквизитлары (документ төре, сериясе һәм номеры, кем тарафыннан бирелүе), яшәү урыны, теркәлү урыны, телефон номеры (шул исәптән кәрәзле телефон), электрон почта адресы, Россия Федерациясе кредит оешмасында ачылган исәп-хисап счеты турында белешмәләр), ИНН, СНИЛС |

Әлеге ризалык имзаланган көннән алып 1 (бер) ел гамәлдә була.

Персональ белешмәләрнең субъекты үз персональ белешмәләрен эшкәртүгә әлеге ризалыкны, бу хакта операторга язмача хәбәр итеп, кире алырга хокуклы.

Персональ белешмәләрнең субъекты үз персональ белешмәләрен эшкәртүгә әлеге ризалыкны кире алган очракта оператор аларны эшкәртүне туктатырга яисә туктатуны

тәэмин итәргә (персональ белешмәләрне эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча башка затка тапшырылган булса) һәм, персональ белешмәләрне эшкәртү өчен аларны саклау башкача кирәк булмаса, ризалыкны кире алу турында мөрәҗәгать кергән көннән алып утыз көн эчендә персональ белешмәләрне юкка чыгарырга яисә юкка чыгаруны тәэмин итәргә (персональ белешмәләрне эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча башка затка тапшырылган булса) тиеш. Күрсәтелгән вакыт эчендә персональ белешмәләрне юкка чыгару мөмкинлеге булмаган очракта, оператор аларны блокировать итә яисә блокировать итүне тәэмин итә (персональ белешмәләрне эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча башка затка тапшырылган булса) һәм  персональ белешмәләрне иң күп дигәндә алты ай эчендә юкка чыгара.

_______________________________________________/__________

персональ белешмәләр субъектының Ф.И.Ат ис. (булган очракта күрсәтелә) һәм имзасы

Дата _________________

Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга
юнәлдерелгән
социаль реклама конкурсын үткәрү турында
нигезләмәгә
3 нче кушымта

(тәкъдим ителә торган форма)

**Тарату өчен персональ белешмәләр субъекты тарафыннан рөхсәт ителгән персональ белешмәләрне эшкәртүгә ризалык**

Мин,

_____________________________________________________________________________,
(фамилия, исем, атасының исеме (булган очракта) рус телендә)

_____________________________________________________________________________,
(почта адресы)

_____________________________________________________________________________,
(электрон почта адресы)

_____________________________________________________________________________,
(телефон номеры)

«Персональ белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның $10^1$ статьясы нигезендә «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына (ОГРН 1031621014765, ОКТМО 92701000, ОКПО 14912163) юридик адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 йорт) сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга юнәлдерелгән социаль реклама конкурсында катнашуга бәйле рәвештә үземнең персональ белешмәләрне таратуга (шул исәптән башкаларга тапшыруга, бирүгә) ризалыгымны бирәм.

Эшкәртүгә ризалык бирелә торган персональ белешмәләрнең категориясе һәм исемлеге

| N т/с | Персональ белешмәләр | Ризалык | |
|---|---|---|---|
| | | Әйе | Юк |
| | Гомуми персональ белешмәләр | | |
| | Фамилия | | |
| | Исем | | |
| | Атасы исеме (булган очракта) | | |
| | Җенесе | | |
| | Туган ел, ай, дата һәм урын | | |
| | Шәхесне таныклаучы документ (төре, | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | сериясе, номеры, кем тарафыннан кайчан бирелгән) | | |
| | Яшәү һәм теркәлү урыны | | |
| | Телефон номеры | | |
| | Электрон почта адресы | | |
| | Россия Федерациясе кредит оешмасында ачылган счет | | |
| | ИНН | | |
| | Һөнәр<br>СНИЛС | | |

Эшкәртү өчен шартлар һәм тыю билгеләнә торган персональ белешмәләрнең категориясе һәм исемлеге

| N т/с | Персональ белешмәләр | Билгеләнә торган шартлар һәм тыюлар исемлеге |
|---|---|---|
| **1. [Персональ белешмәләрнең категориясе]** | | |
| | **[Персональ белешмәләрнең исемлеге]** | |

Искәрмә. Күрсәтелгән таблица персональ белешмәләр субъектының теләге буенча, персональ белешмәләрне эшкәртүне гамәлгә ашыра торган оператор тарафыннан чикләүләрсез тутырыла.

Шартлар һәм тыюлар операторның чикләнмәгән яисә кайбер даирә затларына әлеге персональ белешмәләрне таратуга һәм (яисә) тапшыруга бәйле гамәлләрен чикләүне йә тыюны күздә тота.

Ризалыкта өстәмә шартлар да күрсәтелергә мөмкин, алар алынган персональ белешмәләрне эшкәртүне гамәлгә ашыра торган оператор тарафыннан мәгълүмат кайбер хезмәткәрләргә генә җиткерелә торган эчке элемтәләр буенча йә мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша тапшыруны, яки алынган персональ белешмәләрне тапшырмауны күздә тота

Операторның персональ белешмәләр субъектының персональ белешмәләре чикләнмәгән яисә кайбер даирә затларына тапшырылырга мөмкин мәгълүмат ресурслары турында белешмәләр: http://tatmedia.tatarstan.ru/.

Әлеге ризалык ________________________________ срокта гамәлдә була.

**(ризалыкның гамәлдә булу срогы)**

Персональ белешмәләр субъекты, операторга язмача хәбәр итеп, үзенең персональ белешмәләрен эшкәртүгә бирелгән ризалыктан баш тартырга хокуклы.

Персональ белешмәләр субъекты, операторга язмача хәбәр итеп, үзенең персональ белешмәләрен эшкәртүгә бирелгән ризалыктан баш тарткан очракта

оператор мондый баш тартуны алган көннән алып иң күбе утыз көн эчендә аларны эшкәртүне туктатырга яисә туктатуны тәэмин итәргә (әгәр бу эш оператор кушуы буенча башка зат тарафыннан башкарылса) һәм, элек куелган максатлар өчен персональ белешмәләрне эшкәртү башкача таләп ителмәсә, персональ белешмәләрне юкка чыгарырга яисә юкка чыгаруны тәэмин итәргә (әгәр бу эш оператор кушуы буенча башка зат тарафыннан башкарылса) тиеш.

Күрсәтелгән срокта персональ белешмәләрне юкка чыгару мөмкинлеге булмаган очракта, оператор мондый персональ белешмәләрне блокировать итә яисә блокировать итүне тәэмин итә (әгәр бу эш оператор кушуы буенча башка зат тарафыннан башкарылса) һәм персональ белешмәләрне алты айдан артмаган срокта юкка чыгаруны тәэмин итә.

________________

(персональ белешмәләр субъекты имзасы

________________

(число, ай, ел)

Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга
юнәлдерелгән
социаль реклама конкурсын
үткәрү турында
нигезләмәгә
4 нче кушымта

(тәкъдим ителә торган форма)

**14 яшькә җиткән балигъ булмаган затның персональ белешмәләрен эшкәртүгә ризалык**

Мин,_______________________________________________________________,
(персональ белешмәләр субъекты ата-анасының (законлы вәкиленең ) фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)

шәхесне таныклаучы төп документым (паспорт ) _______________________________________________

(персональ белешмәләр субъекты ата-анасының (законлы вәкиленең ) документы, серия, номер, бирелгән дата һәм биргән орган)

яшәү адресым_______________________________________________________
(персональ белешмәләр субъекты ата-анасының (законлы вәкиленең ) теркәлү урыны адресы

_______________________________________________________________,
«Персональ белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына (алга таба – оператор) (адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 йорт) сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга юнәлдерелгән социаль реклама конкурсында катнашуга бәйле рәвештә үземнең персональ белешмәләрне эшкәртүгә, аларны җыюны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, төгәлләштерүне (яңартуны, үзгәртүне), алардан файдалануны, аларны таратуны (шул исәптән башкаларга тапшыруны), үз исемемнән башка файдалануны, блокировать итүне, юкка чыгаруны да кертеп, ризалыгымны бирәм.

Эшкәртүгә ризалыгымны бирә торган персональ белешмәләрнең исемлеге:

| | |
|---|---|
| Эшкәртүгә ризалыгымны бирә торган персональ белешмәләрнең исемлеге: | (фамилия, исем, атасы исеме, җенес, туган көн һәм урын, гражданлык, шәхесне таныклаучы документның реквизитлары (документ төре, сериясе һәм номеры, кем тарафыннан бирелүе), яшәү урыны, теркәлү урыны, телефон номеры (шул исәптән кәрәзле телефон), электрон почта адресы, Россия Федерациясе кредит оешмасында ачылган исәп-хисап счеты турында белешмәләр), ИНН, СНИЛС |

Әлеге ризалык имзаланган көннән алып 1 (бер) ел гамәлдә була.

Персональ белешмәләрнең субъекты үз персональ белешмәләрен эшкәртүгә әлеге ризалыкны, бу хакта операторга язмача хәбәр итеп, кире алырга хокуклы.

Персональ белешмәләрнең субъекты үз персональ белешмәләрен эшкәртүгә әлеге ризалыкны кире алган очракта оператор аларны эшкәртүне туктатырга яисә туктатуны тәэмин итәргә (персональ белешмәләрне эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча башка затка тапшырылган булса) һәм, персональ белешмәләрне эшкәртү өчен аларны саклау башкача кирәк булмаса, ризалыкны кире алу турында мөрәҗәгать кергән көннән алып утыз көн эчендә персональ белешмәләрне юкка чыгарырга яисә юкка чыгаруны тәэмин итәргә (персональ белешмәләрне эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча башка затка тапшырылган булса) тиеш. Күрсәтелгән вакыт эчендә персональ белешмәләрне юкка чыгару мөмкинлеге булмаган очракта, оператор аларны блокировать итә яисә блокировать итүне тәэмин итә (персональ белешмәләрне эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча башка затка тапшырылган булса) һәм  персональ белешмәләрне иң күп дигәндә алты ай эчендә юкка чыгара.

Персональ белешмәләрнең ата-ана (законлы вәкил) эшкәртүгә шартлар куя һәм аны тыя торган категорияләре һәм исемлеге (персональ белешмәләр субъектының теләге буенча тутырыла)

____________________________________________________________

____________________________________________________________

Алынган персональ белешмәләр аларны эшкәртүче операторга, мәгълүматны аерым бер затлар гына күрерлек итеп, аның эчке челтәре буенча гына йә мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрен кулланып тапшырылырга мөмкин булган яисә алынган персональ мәгълүматларны тапшыру рөхсәт ителми торган шартлар (персональ белешмәләр субъектының теләге буенча тутырыла):

| __________________________ | __________ | ______________ |
|---|---|---|
| (Ф.И.Ат.ис. (персональ белшмәләр субъекты ата-анасы (законлы вәкиле) | (имза) | (дата) |

| __________________________ | __________ | ______________ |
|---|---|---|
| (Ф.И.Ат. ис. (персональ белешмәләр субъекты) | (имза) | (дата) |

Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга юнәлдерелгән
социаль реклама конкурсын үткәрү
турында нигезләмәгә
5 нче кушымта

(тәкъдим ителә торган форма)

**14 яшькә җиткән балигъ булмаган затның тарату өчен персональ белешмәләр субъекты тарафыннан рөхсәт ителгән персональ белешмәләрне эшкәртүгә ризалык**

Мин,_______________________________________________________________,
(персональ белешмәләр субъекты ата-анасының (законлы вәкиленең ) фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)
шәхесне таныклаучы төп документым (паспорт )
_______________________________________________________________
(персональ белешмәләр субъекты ата-анасының (законлы вәкиленең ) документы, серия, номер, бирелгән дата һәм биргән орган)

яшәү адресым_______________________________________________________
(персональ белешмәләр субъекты ата-анасының (законлы вәкиленең ) теркәлү урыны адресы
_______________________________________________________________,
«Персональ белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның $10^1$ статьясы нигезендә «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына (ОГРН 1031621014765, ОКТМО 92701000, ОКПО 14912163) юридик адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 йорт) сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга юнәлдерелгән социаль реклама конкурсында катнашуга бәйле рәвештә үземнең персональ белешмәләрне таратуга (шул исәптән башкаларга тапшыруга, бирүгә) ризалыгымны бирәм.

Эшкәртүгә ризалык бирелә торган персональ белешмәләрнең категориясе һәм исемлеге

| Т/с | Персональ белешмәләр | Ризалык | |
|---|---|---|---|
| | | Әйе | Юк |
| Гомуми персональ белешмәләр | | | |
| | Фамилия | | |
| | Исем | | |
| | Атасы исеме (булган очракта) | | |
| | Җенесе | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Туган ел, ай, дата һәм урын | | |
| | Шәхесне таныклаучы документ (төре, сериясе, номеры, кем тарафыннан кайчан бирелгән) | | |
| | Яшәү һәм теркәлү урыны | | |
| | Телефон номеры | | |
| | Электрон почта адресы | | |
| | Россия Федерациясе кредит оешмасында ачылган счет | | |
| | ИНН | | |
| | Һөнәр<br>СНИЛС | | |

Эшкәртү өчен шартлар һәм тыю билгеләнә торган персональ белешмәләрнең категориясе һәм исемлеге

| Т/с | Персональ белешмәләр | Билгеләнә торган шартлар һәм тыюлар исемлеге |
|---|---|---|
| **1. [Персональ белешмәләрнең категориясе]** | | |
| | **[Персональ белешмәләрнең исемлеге]** | |

Искәрмә. Күрсәтелгән таблица персональ белешмәләр субъектының теләге буенча, персональ белешмәләрне эшкәртүне гамәлгә ашыра торган оператор тарафыннан чикләүләрсез тутырыла.

Шартлар һәм тыюлар операторның чикләнмәгән яисә кайбер даирә затларына әлеге персональ белешмәләрне таратуга һәм (яисә) тапшыруга бәйле гамәлләрен чикләүне йә тыюны күздә тота.

Ризалыкта өстәмә шартлар да күрсәтелергә мөмкин, алар алынган персональ белешмәләрне эшкәртүне гамәлгә ашыра торган оператор тарафыннан мәгълүмат кайбер хезмәткәрләргә генә җиткерелә торган эчке элемтәләр буенча йә мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша тапшыруны, яки алынган персональ белешмәләрне тапшырмауны күздә тота

Операторның персональ белешмәләр субъектының персональ белешмәләре чикләнмәгән яисә кайбер даирә затларына тапшырылырга мөмкин мәгълүмат ресурслары турында белешмәләр: http://tatmedia.tatarstan.ru/.

Әлеге ризалык ______________________________ срокта гамәлдә була.

**(ризалыкның гамәлдә булу срогы)**

Персональ белешмәләр субъекты, операторга язмача хәбәр итеп, үзенең персональ белешмәләрен эшкәртүгә бирелгән ризалыктан баш тартырга хокуклы.

Персональ белешмәләр субъекты, операторга язмача хәбәр итеп, үзенең персональ белешмәләрен эшкәртүгә бирелгән ризалыктан баш тарткан очракта оператор мондый баш тартуны алган көннән алып иң күбе утыз көн эчендә аларны эшкәртүне туктатырга яисә туктатуны тәэмин итәргә (әгәр бу эш оператор кушуы буенча башка зат тарафыннан башкарылса) һәм, элек куелган максатлар өчен персональ белешмәләрне эшкәртү башкача таләп ителмәсә, персональ белешмәләрне юкка чыгарырга яисә юкка чыгаруны тәэмин итәргә (әгәр бу эш оператор кушуы буенча башка зат тарафыннан башкарылган очракта) тиеш.

Күрсәтелгән срокта персональ белешмәләрне юкка чыгару мөмкинлеге булмаган очракта, оператор мондый персональ белешмәләрне блокировать итә яисә блокировать итүне тәэмин итә (әгәр бу эш оператор кушуы буенча башка зат тарафыннан башкарылса) һәм персональ белешмәләрне алты айдан артмаган срокта юкка чыгаруны тәэмин итә.

| | | |
|---|---|---|
| ______________________________ (Ф.И.Ат. ис. (персональ белешмәләр субъекты ата-анасы (законлы вәкиле) | __________ (имза) | ______________ (дата) |
| ______________________________ (Ф.И.АТ. ис. (персональ белешмәләр субъекты) | __________ (имза) | ______________ (дата) |